РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«21» август, 2015 ел Олы Кайбыч ав. № 290

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрүне тәртипкә салу максатларында “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Кайбыч муниципаль районы Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2009 елның 25 июнендәге 182 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга. "Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс турында нигезләмәне раслау хакында".

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Советының законлылыкны һәм хокук тәртибен саклау буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе-
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының 2015 елның 21.08
290 номерлы карарына 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмә

1. "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе һәм шартлары билгеләнә (алга таба - конкурс).

2. Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларының конкурс нигезендә биләнә торган түбәндәге исемлеге билгеләнә:

- муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары;
- муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары;
- муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары;
- муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары.

Югарыда күрсәтелгән вазыйфалар исемлеге муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексында билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфалары классификациясе нигезендә китерелгән.

3. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Кайбыч районы башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

4. Конкурс гражданнарның үз сәләтләре һәм һөнәри әзерлекләре нигезендә муниципаль хезмәткә бертигез дәрәҗәдә керү хокукына, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итә.

5. Җирле үзидарә органнарында конкурс җирле үзидарә органы җитәкчесе, тиешле органда вакантлы (муниципаль хезмәткәр тарафыннан биләнмәгән) муниципаль хезмәт вазыйфасы булганда, функциональ, тармак органы җитәкчесе карары буенча игълан ителә.

6. Конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасына сайланулы муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләрен үтәүне турыдан-туры тәэмин итү өчен гамәлгә ашырыла торган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә;

2) вакытлы хезмәт шартнамәсе төзегәндә;

3) җирле үзидарә органы бетерелүгә, аның штаты кыскаруга (муниципаль хезмәт вазыйфалары кыскаруга) бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәте башка вазыйфага билгеләнгәндә;

4) билгеләнгән тәртиптә төзелгән кадрлар резервында торучы муниципаль хезмәткәр (граждан) муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә.

Конкурс аның буенча вазыйфаи бурычларның үтәлеше дәүләт серен

тәшкил итүче мәгълүматлардан файдалануга бәйле муниципаль хезмәтнең аерым муниципаль вазыйфаларына билгеләнгәндә үткәрелмәскә мөмкин, .

7. Конкурс муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның муниципаль хезмәт вазыйфасына квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

8. Конкурста катнашу хокукына Россия Федерациясе дәүләт телен белгән һәм билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килә торган, Россия Федерациясе Законының 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы 13 статьясында муниципаль хезмәткә бәйле чикләүләр буларак билгеләнгән шартлар булмаганда,18 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданнары ия була.

9. Җирле үзидарә органы “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында конкурс уздыру һәм конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында игълан игълан итә.

10. Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрү турындагы хәбәрдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) вакантлы вазыйфаның тулы исеме;

2) әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга карата куела торган таләпләрне үз эченә алган конкурс уздыру шартлары;

3) әлеге Нигезләмәнең 10 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документлар кабул ителә торган срок;

4) конкурс турында тулы мәгълүмат чыганагы турында белешмәләр (телефон, факс, электрон почта, электрон адресы).

11. Конкурсны уздыру турындагы хәбәр конкурс уздырылган көнгә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла.

12. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы конкурс комиссиясенә түбәндәгеләрне тапшыра:

1) конкурс комиссиясе рәисе исеменә шәхси гариза;

2) әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә форма буенча кулдан тутырылган һәм имзаланган автобиографияс,анкета;

3) паспорт яисә аны алмаштыручы документ күчермәсе;

4) кирәкле һөнәри белем алуны, эш һәм квалификация стажын раслый торган документлар:

гражданның хезмәт (хезмәт) эшчәнлеген раслый торган хезмәт кенәгәсе яисә башка документ күчермәсен (әгәр булса);

һөнәри белем турында документларның, шулай ук гражданның теләге буенча - өстәмә һөнәри белем турында, гыйльми дәрәҗә бирү турында, гыйльми исем бирү турында, эш (хезмәт) урыны буенча нотариаль яисә кадрлар хезмәтләре тарафыннан расланган документларның күчермәләре;

5) конкурс үткәрү елына кадәрге календарь ел өчен гражданның мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук конкурс үткәрелүгә кадәрге календарь ел өчен керемнәре, ир яисә хатынның (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларында билгеләнгән форма буенча гражданның муниципаль

хезмәт вазыйфаларына муниципаль хезмәткәрләр билгән очракта муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлекләре тарафыннан каралган муниципаль хезмәт вазыйфаларына кергәндә белешмәләр;

6) гражданның муниципаль хезмәткә керүгә яисә аны узуга Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен билгеләнгән рәвештә мондый авырулар исемлегендә каралган авыруы булмау турында медицина учреждениесе бәяләмәсе;

7) мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы;

8) Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында физик затны исәпкә кую турында таныклык;

9) хәрби исәпкә алу документлары - хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен һәм хәрби хезмәткә чакырылучы затлар өчен.

13. Гариза биргән затка документларның исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, документлар алуда расписка бирелә.

14. Муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән чикләүләр булганда, граждан конкурста катнашуга рөхсәт ителми.

Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашудан баш тарткан очракта, граждан әлеге карарга суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашучы теләсә кайсы вакытта үз гаризасын кире кайтара ала.

15. Тәкъдим ителгән документларны кабул итү конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла. Әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында күрсәтелгән документлар конкурс үткәрү турында хәбәр басылып чыккан көннән соң 20 көн эчендә конкурс комиссиясенә тапшырыла.

16. Документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшыру яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданга аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез була.

17. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе турындагы нигезләмә һәм хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү нигезендә гамәлгә ашырыла.

18. Конкурс гаризалар бирү срогы тәмамланган көннән алып 10 көннән дә соңга калмыйча уздырыла.

19. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар үткәрү өчен җирле үзидарә органының (вазыйфаи затның) хокукый акты белән конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясенең персональ составы, аның эш сроклары һәм тәртибе җирле үзидарә органының (вазыйфаи затның) хокукый акты белән билгеләнә.

20. Конкурс комиссиясе составына җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм (яисә) ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук бәйсез экспертлар буларак чакырыла торган башка оешмалар вәкилләре керә.

21. Конкурс комиссиясе комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзаларыннан тора.

Конкурс комиссиясе рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аның эшен оештыра.

Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары конкурс комиссиясе рәисе вазыйфаларын ул булмаган очракта башкара.

Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе утырышларына материаллар әзерләүне тәэмин итә, утырышны чакыру турында конкурс комиссиясе әгъзаларына хәбәр итә, комиссия әгъзаларына көн тәртибе турында хәбәр итә, гаризаларны, документларны кабул итә һәм терки, конкурс комиссиясе карарлары проектларын әзерли, кандидатларга конкурс үткәрү нәтиҗәләре турында хәбәр итүне тәэмин итә, конкурс комиссиясе рәисе кушуы буенча башка функцияләр башкара.

22. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы һәм Кайбыч муниципаль районы җирлекләре арасында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы килешүләр нигезендә конкурс уздыру Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башлыгы тарафыннан төзелгән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурсны оештыру һәм уздыру буенча конкурс комиссиясенә йөкләнә.

23. Күрсәтелгән документлар нигезендә конкурс комиссиясе конкурста катнашуга кандидатларны кертү турында карар кабул итә.

24. Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны алар биргән мәгариф, муниципаль, граждан яисә башка дәүләт хезмәте узу, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турындагы документлар нигезендә бәяли.

Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә конкурс комиссиясе вакантлы вазыйфага карата тиешле квалификация таләпләреннән, вазыйфаи инструкция таләпләреннән, шулай ук муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

25. Кандидатларны тикшерү һәм конкурс нигезендә сайлап алу конкурс комиссиясе утырышларында гамәлгә ашырыла.

Конкурс комиссиясе утырышы муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына кимендә ике кандидат булганда уздырыла һәм, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе карарлары утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Тавышлар тигез булганда, хәлиткеч комиссия рәисе тавышы була.

26. Конкурс процедураларын үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) кандидат муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына карата квалификация таләпләренә туры килә;

2) кандидат муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына карата квалификация таләпләренә туры килми;

3) кандидатны кадрлар резервына кертү өчен тәкъдим ителде.

27. Конкурс комиссиясе карары кандидат булмаганда кабул ителә.

28. Конкурс комиссиясе карары һәм конкурс комиссиясенең тавыш бирү

нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул утырышта катнашкан конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

29. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча яллаучы вәкиле (эш бирүче) хезмәт шартнамәсе төзи һәм конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан сайлап алынган кандидатларның берсе муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына билгеләп куя.

30. Әгәр конкурс үткәрү нәтиҗәсендә муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасына квалификация таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаган булса, җирле үзидарә органы җитәкчесе йә яллаучының (эш бирүче) вәкиле вазыйфаларын башкарырга вәкаләтле башка вазыйфаи зат кабат конкурс уздыру турында карар кабул итә.

31. Конкурс комиссиясе конкурста катнашкан кандидатларга конкурс нәтиҗәләре турында язма рәвештә ул тәмамланган көннән соң 7 көн эчендә хәбәр итә.

32. Муниципаль хезмәтнең конкурста катнашуга кертелмәгән вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучыларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәмамланган көннән алып өч ел эчендә аларга язма гариза буенча кайтарылырга мөмкин. Шушы вакыт узганчы документлар җирле үзидарә органнары архивында саклана, шуннан соң юк ителергә тиеш.

33. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкалар) кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

34. Кандидат конкурс комиссиясе карарына гамәлдәге законнар нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.